**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**22 ноябрь 2022 ел** **№2**

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Урманай авыл җирлеге Урманай торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Беек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Урманай авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар (янгын инвентаре сатып алу, янгын сүндерү гидрантларын тоту, урнаштыру һәм ремонтлау, янгын техникасын тоту (килешү буенча хезмәт хакы түләү, трактор белән техниканы арендалау, запас частьләр һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);
- Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, су чыганакларын санитар саклау зоналарын төзекләндерү, ЗСО проектларын әзерләү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, эчә торган суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү);
- Урманай авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (территорияне кипкән агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырылган чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, трактористка механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәт өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре ечен шартнамә буенча эшләр өчен түләү, МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары һәм запчастьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту хезмәте күрсәтү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге башлыгы Э.Р.Абдуллина